СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**17.12.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 177**

Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре Советының «Зеленодольск шәһәре территориясендә муниципаль контроль турында нигезләмәләрне раслау хакында» 2021 елның 17 декабрендәге 68 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (Зеленодольск шәһәре Советының 2022 елның 24 мартындагы 75 номерлы, 2023 елның 14 июнендәге 118 номерлы, 2023 елның 28 декабрендәге 144 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре Советының «Зеленодольск шәһәре территориясендә муниципаль контроль турында нигезләмәләрне раслау хакында» 2021 елның 17 декабрендәге 68 номерлы карарына (Зеленодольск шәһәре Советының 2022 елның 24 мартындагы 75 номерлы, 2023 елның 14 июнендәге 118 номерлы, 2023 елның 28 декабрендәге 144 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Зеленодольск шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешенә муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.1. «Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге» 1 нче кушымтаны әлеге карарга кушымта да каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

**Зеленодольск шәһәре Мэры,**
**Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**

Зеленодольск муниципаль районы
Советының 2024 елның 16 декабрендәге
177 номерлы карарына
«Татарстан Республикасы Зеленодольск
шәһәре Советының 2021 елның
17 декабрендәге 68 номерлы карары белән
(Зеленодольск шәһәре Советының 2022
елның 24 мартындагы 75 номерлы, 2023
елның 14 июнендәге 118 номерлы, 2023
елның 28 декабрендәге 144 номерлы
карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне
һәм өстәмәләрне исәпкә алып) расланган
Зеленодольск шәһәре территориясендә
җылылык белән тәэмин итү объектларын
төзү, реконструкцияләү һәм (яисә)
модернизацияләү буенча бердәм җылылык
белән тәэмин итүче оешма тарафыннан
йөкләмәләр үтәлешенә муниципаль
контроль турындагы нигезләмәгә
1 нче кушымта

**Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге**

Зеленодольск шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары:

- Рәттән өч ай эчендә бер үк җылылык белән тәэмин итү объектында ике һәм аннан күбрәк авария булу;
- Рәттән өч ай эчендә җылылык белән тәэмин итүнең ышанычлылыгы, шулай ук бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма һәм җылылык энергиясен кулланучы арасында барлыкка килә торган каршылыклар мәсьәләләре буенча кулланучыларның ике һәм аннан күбрәк мөрәҗәгатьләре;
- Җылылык белән тәэмин итү схемасында аның өчен билгеләнгән җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның ышанычлылыгын һәм энергетик нәтиҗәлелеген арттыру өчен кирәкле җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү чаралары исемлеген бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан үтәмәү.»